**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы**
**Кошман авыл җирлегенең Кошман торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**«27» ноябрь, 2021 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 22 ноябрендә 14 сәгатьтә, 2021 елның 23 ноябрендә 10 сәгатьтә, 2021 елның 24 ноябрендә 10 сәгатьтә, 2021 елның 25 ноябрендә 10 сәгатьтә, 2021 елның 26 ноябрендә 13 сәгатьтә, 2021 елның 27 ноябрендә 10 сәгатьтә булган гражданнар җыеннары нәтиҗәсе белән «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Кошман торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә караган түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- буаны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- кое ремонтлау һәм аның тирәсен төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;
- сууткәргеч челтәрен ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- су башняларын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;
- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә."

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 557 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар

саны - 291, бу 52,24 % тәшкил итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 291 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең Кошман торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2.« Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Кошман торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә караган түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- буаны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- кое ремонтлау һәм аның тирәсен төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;
- сусуүткәргеч челтәрен ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- су башняларын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;
- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә" – кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Сафина